Титаренко, Д. «Тын да алмыйча тыңладылар» / Д. Титаренко // Шәһри Чаллы. – 2025. - №10 (12 февраль). – Б. 20



Бөек Жиңүнең 80 еллыгына

# «Тын да алмыйча тыңладылар»

**Чаллының Үзәк балалар китапханәсендә укучылар өчен Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Яр Чаллы Бөек Ватан сугышы елларында» дип аталган туган якны өйрәнү укулары узды. Чарага кунак буларак журналист һәм волонтёр Нариман Габдрахманов чакырылды.**



Ул Тарловка бистәсендәге хәрби госпитальнең, сугыш елларында ничек эшләвен, Санкт-Петербург музее архивларында шушы госпиталь хезмәтенә кагылышлы күп документларны өйрәнүен сөйләде.

Мәгълум булганча, Нариман Хәмит улы Тарловка посёлогындагы 4089 нчы санлы хәрби госпитальдә вафат булган солдатлар кумелгән зиярәттә мемориал ясауны башлап йөрүче дә. Сугыш вакытында безнең шәһәр һәм авылларга бик күп кеше эвакуацияләнгән булган. Алар ничек яшәгәннәр кайларда эшләгәннәр, кунагыбыз белгәннәрен җентекләп сөйләп бирде. Чара барышында кызлар һәм малайларның да күп кенә сораулары булды.

Китапханәчеләр дә укучыларга 1941-1945 елларда Чаллы районы авылларында хатын-кызларның, балаларның, картларның көнне төнгә ялгап эшләүләре хакында күп кенә мәгълүмат җиткерделәр. Төп авырлык шу- лар җилкәсенә төшкән бит. Тракторлар юк, хәтта атлар да санаулы булган. Халык ач килеш сабанга җигелеп җир сөргән, урман кискән, икмәк урган. Төннәр буе утырып, фронтка оекбашлар бәйләгән.

Укучылар бу вакыйгаларны тын да алмыйча тыңлап утырдылар. Шу- лай ук, бөтен илебезгә билгеле булган герой шәһәрдәшләребез хакындагы әңгәмә дә кызлар һәм малайларнық йөрәгенә үтеп керде.

**Диләрә Титаренко, Балалар үзәк китапханәсе мөдире**